| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>УРАЗАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ<br><br>423750, Уразай авылы,<br>Үзәк ур., 4 нчы йорт.<br>Тел.3-44-62 |  | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА УРАЗАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br><br>423750, дер.Уразаево,<br>ул. Центральная,дом 4,<br>Тел. 3-44-62 |
|---|---|---|

**Карар**
**05 ноябрь 2019 ел**

**Постановление**
**№2**

Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Куян,Уразай,Шәрип,Ильчебай Мерәс торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Уразай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы,Уразай авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1.Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенен Куян авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 18 ноябренә 11 сэг.00 мин. билгеләргә.

2.Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенен Уразай, Шэрип, Ильчебай, Мерэс авылларында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 20 ноябренә 14 сэг.00 мин. билгеләргә.

3.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

-торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;

- сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;

- рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру ;

- зират территориясендә агач кисү;

- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;

-ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;

- зират коймасын ремонтлау;

-юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдерлау, кардан чистарту)

- һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү ;

- җирлек торак пунктларында хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм киртәләү;

-торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру;

-урамнарнын яктырту электр челтәрләрен карап тоту;

- декларация алдыннан ГТСны тикшерү.

**"ӘЙЕ"** **"ЮК"**

4. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: 2019 елнын 18 ноябре көнне Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Куян авылы, Узэк урамы, 57 йорт, 2019 елнын 20 ноябре көнне Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Шэрип авылы, Узэк урамы, 5 йорт.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

7. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Уразай авыл жирлеге башлыгы: Шарипов Р.Р.